Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XIV-3**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 15 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыруны тәртипкә салу максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 17 маддәсе, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 20 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 12 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 10.2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының «Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында вакантлы муниципаль вазыйфа биләүгә конкурс турында Нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 18 июнендәге XXIX-2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2016 елның 15 декабрендәге
XIV-3 номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә белән «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 17 маддәсе, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 20 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 12 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 10.2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе һәм шартлары билгеләнә (алга таба - вакантлы вазыйфа). Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

2. Җирле үзидарә органы җитәкчесе яисә яллаучы (эш бирүче) вәкиле вазыйфаларын муниципаль берәмлек исеменнән башкарырга вәкаләтле зат вакантлы (муниципаль хезмәткәр тарафыннан билгеләнмәгән) муниципаль хезмәт вазыйфалары булганда конкурс үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

3. Конкурс муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның муниципаль хезмәт вазыйфасына квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

4. Конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясе дәүләт телен белгән һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән вакантлы вазыйфага квалификация таләпләренә туры килгән, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 13 маддәсендә муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр буларак күрсәтелгән шартлар булмаганда, 18 яшькә җиткән гражданнар ия.

5. Конкурс үткәрү һәм конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында, шулай ук муниципаль хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсе проекты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге веб-адресы буенча урнаштырыла: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырыла: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук башка гаммәви мәгълүмат чараларында да басылып чыгарга мөмкин.

6.Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрү турындагы хәбәрдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) вакантлы вазыйфаның тулы исеме (аталышы);

2) конкурс уздыру шартлары, әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга куела торган таләпләрне үз эченә ала;

3) конкурс уздыру датасы, вакыты һәм урыны;

4) документлар кабул ителә торган шушы Нигезләмәнең 8 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты;

5) муниципаль хезмәткәр белән төзелә торган хезмәт шартнамәсе проекты;

6) конкурс турында тулы мәгълүмат чыганагы турында мәгълүматлар (телефон, факс, электрон почта, электрон адресы);

7) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә башка мәгълүматлар.

7.Конкурсны уздыру турындагы хәбәр конкурс уздырылачак көнгә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча басылып чыга.

8.Конкурста катнашырга теләүче затлар конкурс комиссиясенә гариза бирә, аңа түбәндәге документлар теркәлеп бирелергә тиеш:

1) үз куллары белән тутырылган һәм әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә имзаланган анкета, 3 х 4 зурлыгындагы фотосурәт, автобиография;

2) паспортының яисә аны алыштыручы документының төп нөсхәсе һәм күчермәсе (тиешле документ документлар биргәндә һәм конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

3) кирәкле һөнәри белем бирүне, эш һәм квалификация стажын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең төп нөсхәсе һәм күчермәсе, хезмәт шартнамәсе беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;

һөнәри белем турында, шулай ук, гражданның теләге буенча, өстәмә һөнәри белем турында, гыйльми дәрәҗә бирү турында, гыйльми исем бирү турында документларның нотариаль яки эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәтләре тарафыннан расланган төп нөсхәсе һәм күчермәләре;

4) хезмәт шартнамәсе беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы;

5) Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында физик затны исәпкә кую турында таныклык;

6) хәрби исәпкә алу документлары - запаста торучы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;

7) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында конкурста катнашу өчен документлар тапшыру елыннан алдагы ел керемнәре турында мәгълүматлар;

8)муниципаль хезмәткә керүгә каршы килә торган авыру булмау турында медицина оешмасы бәяләмәсе;

9) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматны урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында мәгълүматлар, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән форма буенча муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасына конкурста катнашу өчен документлар тапшыру елыннан алдагы өч календарь ел эчендә аны ачыкларга мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар;

10) муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында, башка норматив хокукый актларда каралган башка документлар.

9. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар махсус журналда теркәлә, анда теркәү номеры бирелә.

Гариза биргән затка документларның исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, раслама бирелә.

10.Граждан конкурста вакантлы вазыйфага квалификация таләпләренә туры килмәү сәбәпле, шулай ук муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә катнаша алмый.

Вакантлы вазыйфаны биләп торуга конкурста катнашуга рөхсәт бирүдән баш тарткан очракта, граждан әлеге карарга законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Вакантлы вазыйфаны биләп торуга конкурста катнашучы һәр мизгелдә үз гаризасын алырга хокуклы.

11. Тапшырыла торган документларны кабул итү һәм тикшерү конкурс комиссиясе сәркатибее тарафыннан башкарыла. Документларның төп нөсхәләре гариза бирүчегә тапшырылган көнне кайтарыла, ә күрсәтелгән документларның күчермәләре эшкә (делога) урнаштырыла.

12.Әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән документлар конкурс комиссиясенә конкурс үткәрү турында хәбәр бастырылганнан соң 20 көн эчендә тапшырыла.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулысынча тапшырмау гражданга аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

13. Конкурс гариза бирү срогы тәмамланганнан соң 10 көн эчендә үткәрелә.

14.Конкурс үткәрү өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы (алга таба-район Башлыгы) конкурс комиссиясе төзи. Конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм вакыты әлеге Нигезләмә белән билгеләнә. Конкурс комиссиясе составы район Башлыгы карары белән раслана.

Конкурс комиссиясе составына җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм (яки) аларга вәкаләтле муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән муниципаль хезмәт һәм кадрлар, юридик (хокукый) бүлекчәләр һәм вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрелә торган бүлекчәләр) керә.

15.Конкурс комиссиясе рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

Конкурс комиссиясе сәркатибе материалларны конкурс комиссиясе утырышларына әзерләүне тәэмин итә, конкурс комиссиясе әгъзаларына утырыш чакыру турында хәбәр итә, комиссия әгъзаларына көн тәртибе турында хәбәр итә, гаризалар, документлар кабул итә һәм теркәп тора, конкурс комиссиясе карарлары проектларын әзерли, конкурс үткәрү нәтиҗәләре турында хәбәр итә, конкурс комиссиясе рәисе кушуы буенча башка функцияләрне башкара.

16.Тәкъдим ителгән документлар нигезендә конкурс комиссиясе дәгъва кылучыларны конкурста катнашырга рөхсәт итү турында карар кабул итә.

17. Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе дәгъвачыларны алар тапшырган белем бирү, граждан яисә башка дәүләт яисә муниципаль хезмәт узу, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турындагы документлар нигезендә бәяли, шулай ук федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган дәгъвачының һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын кулланып, дәгъвачыларның үз программаларын тәкъдим итүләрен дә кертеп, индивидуаль әңгәмә нигезендәге конкурс процедуралары нигезендә.

Дәгъвачыларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә конкурс комиссиясе вакантлы вазыйфага карата тиешле квалификация таләпләреннән, вазыйфаи инструкция таләпләреннән, шулай ук муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

18. Конкурс комиссиясе утырышы кимендә ике дәгъвачы булганда уздырыла.

Дәгъвачыларны конкурс нигезендә сайлап алу һәм фикер алышу конкурс комиссиясе утырышларында гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе карарлары утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда, хәлиткеч комиссия рәисе тавышы була.

19.Конкурс комиссиясе конкурс процедураларын үткәрү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) дәгъвачы муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына карата квалификация таләпләренә туры килә;

2) дәгъвачы муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына карата квалификация таләпләренә туры килми.

20.Конкурс комиссиясе карары дәгъвачы булмаганда кабул ителә.

21.конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре утырышта катнашкан конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, сәркатибе һәм әгъзалары имзалаган карар белән рәсмиләштерелә.

22.Яллаучының (эш бирүче) вәкиле вакантлы вазыйфа биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча хезмәт шартнамәсе төзи һәм конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс нәтиҗәләре буенча сайлап алынган дәгъвачыларның берсен муниципаль хезмәт вазыйфасына билгели.

23.Әгәр конкурс үткәрү нәтиҗәсендә вакантлы вазыйфага квалификация таләпләренә җавап бирүче дәгъвачылар ачыкланмаган булса, җирле үзидарә органы җитәкчесе яисә яллаучының (эш бирүченең) вәкиле вазыйфаларын башкарырга вәкаләтле башка вазыйфаи зат яңа конкурс үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

24.Конкурс комиссиясе конкурста катнашкан дәгъвачыларга конкурс нәтиҗәләре турында язма рәвештә ул тәмамланган көннән соң бер ай эчендә хәбәр итә.

Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат ул тәмамланган көннән алып 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru.

25.Дәгъвачы конкурс комиссиясе карарына гамәлдәге законнар нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

26.Конкурста катнашуга кертелмәгән вакантлы вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучылар һәм конкурста катнашкан дәгъвачылар документлары конкурс тәмамланган көннән алып өч ел дәвамында язма гариза буенча кире кайтарылырга мөмкин. Шушы вакыт узганчы документлар җирле үзидарә органнары архивында саклана, шуннан соң юк ителергә тиеш.

27.Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкалар) дәгъвачыларның үз акчалары исәбеннән башкарыла.

28.Конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә йөкләнә.

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районының
җирле үзидарә органнарында
муниципаль хезмәтнең вакантлы
вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру
тәртибе турындагы Нигезләмәгә
кушымта

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең
2005 елның 26 маендагы 667-р
номерлы Күрсәтмәсе белән расланган

(рәвеш)

АНКЕТА

(үз кулың белән тутырыла)

| фотография өчен урын |
|---|

1. Фамилиясе ________________________
   Исеме ____________________________
   Атасының исеме _______________________

| | |
|---|---|
| 2. Әгәр дә фамилия, исем яки әтисенең исеме үзгәртелсә, аларны кайчан, кайда һәм нинди сәбәп белән үзгәртелүләрен күрсәтегез | |
| 3. Туган көне, ае, елы һәм урыны (авыл, шәһәр, район, өлкә, край, республика, ил) | |
| 4. Гражданлык (әгәр үзгәртсәгез, күрсәтегез, кайчан һәм нинди сәбәп белән, әгәр сез гражданлыкны үзгәртсәгез, шулай ук сәбәбен һәм дәүләтен күрсәтегез ) | |
| 5. Белем (кайчан һәм нинди уку йортлары тәмамлаган, дипломнар номерлары)<br>Диплом буенча әзерлек юнәлеше яисә белгечлек<br>Диплом буенча квалификация | |
| 6. Югары уку йортыннан соңгы һөнәри белем: аспирантура, адъюнктура, докторантура (белем бирү яисә фәнни учреждениенең исеме, тәмамлау елы)<br>Гыйльми дәрәҗә, гыйльми исеме (кайчан бирелде, дипломнар, аттестатлар номерлары) | |
| 7. Россия Федерациясе халыкларының нинди телләрен беләсез һәм чит телләрне беләсезме, нинди дәрәҗәдә (сүзлек белән укыйсызмы һәм тәрҗемә итәсезме, укыйсыз һәм аңлатып бирә аласызмы, иркен сөйләшәсезме) | |
| 8. Федераль граждан хезмәтенең классны чины, дипломатик ранг, хәрби яки махсус дәрәҗә, хокук саклау хезмәтенең классны чины, Россия Федерациясе субъекты граждан хезмәтенең классны чины, дәүләт хезмәтенең квалификация разряды, квалификация разряды яисә муниципаль хезмәтнең классны чины (кем тарафыннан һәм кайчан билгеләнгән) | |
| 9. Хөкем ителдегезме, кайчан һәм нәрсә өчен? (Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенә кергәндә тутырыла) | |

| 10. Эш, хезмәт, уку чорында рәсмиләштерелгән дәүләт серенә керү, аның формасы, номеры һәм датасы (булса) | |
|---|---|

11. Хезмәт эшчәнлеге башланганнан бирле башкарыла торган эш (шул исәптән югары һәм урта махсус уку йортларында уку, хәрби хезмәт, бергәлек буенча эш, эшмәкәрлек һ. б.).

Әлеге пунктны тутырганда оешмаларны ул чакта аталганча атарга, хәрби хезмәтне язарга кирәк, хәрби частьтагы вазыйфасын һәм частьның номерын күрсәтеп.

| Ай һәм ел | | Оешмадагы вазыйфа | Оешманың адресы (ш.и. чит илдә) |
|---|---|---|---|
| башлау | китү | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

12. Дәүләт бүләкләре, башка бүләкләр һәм мактау билгеләре

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

13. Сезнең якын туганнарыгыз (әти, әни, энеләр, сеңелләр һәм балалар), шулай ук ире (хатыны), шул исәптән элеккегеләр.

Туганнары фамилиясен, исемен, әтисенең исемен үзгәртсә, аларның элеккеге фамилиясен, исемен, әтисенең исемен дә күрсәтергә кирәк.

| Туганлык дәрәҗәсе | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган ел, ае, көне, урыны | Эш урыны (оешманың аталышы, адресы), вазыйфа | Йорт адресы (теркәлү һәм фактта яшәү адреслары) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

14. Сезнең якын туганнарыгыз (әтиегез, әниегез, абый-энеләрегез, апа-сеңелләрегез һәм балаларыгыз), ш.и. элеккеләр, шулай ук чит илдә даими яшәүчеләр һәм (яисә) башка дәүләткә даими яшәү урынына чыгу өчен документлар рәсмиләштерүче ирегез (хатыныгыз) ______________________________

______________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме,чит илдә кайчаннан бирле яшиләр)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

15. Чит илдә булу (кайчан, кайда, нинди максат белән) ____________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

16. Хәрби хезмәткә мөнәсәбәт һәм хәрби дәрәҗә ____________

______________________________________________________________________

17. Йорт адресы (теркәлү һәм фактта яшәү адреслары), телефон номеры (яки башка теләсә нинди элемтәнең) _______________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

18. Паспорт яки аны алыштыручы документ ___________________________

(серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

19. Чит ил паспортының булуы __________________________________

(серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

20. Мәҗбүри пенсия иминиятләштерүенең иминият таныклыгы номеры (булса) __________________________________________

21. ИНН (булса) ______________________________________________

22. Өстәмә мәгълүматлар (сайланулы вәкиллекле органнарда катнашу, үзегез турында хәбәр итәргә теләгән башка мәгълүмат) _____

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

23Билгеле булганча, үзем турында ялган мәгълүматлар анкетада хәбәр итү һәм минем квалификация таләпләренә туры килмәвем Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенә яисә Россия Федерациясендә муниципаль хезмәткә конкурста катнашудан һәм кабул итүдән баш тартуга китерергә мөмкин. Миңа карата тикшерү чаралары үткәрүгә риза.

"__" __________, 20___ ел Имза _____________

М.У. Хезмәт эшчәнлеге, хәрби хезмәт турында һәм рәсмиләштерелә торган затның укуы турында фотография һәм мәгълүматлар шәхесне раслаучы документларга, хезмәт кенәгәсендә, мәгариф һәм хәрби хезмәт турындагы документларга туры килә.

"__" _________, 20__ел __________________________________________

(имза, комиссия сәркатибенең фамилиясе)